СОВЕТ НИЖНЕТАКАНЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Банковская, д.17, с. Нижний Таканыш, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422140

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ТӘКӘНЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Банк ур., 17 нче йорт, Түбән Тәкәнеш авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422140

тел.(факс): (85563) 2-63-21; e-mail: Nakt.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар | Решение

«19» июль 2024ел | №1-35

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-7 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнешавыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Прокурорның 2024 елның 15 мартындагы 02-08-02-2024 номерлы протесты, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 79 статьясына һәм “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законның 28_1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында” 2024 елның 23 мартындагы 54-ФЗ номерлы,“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007елның 2 мартындагы N 25-ФЗ федераль законнар, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. ВнестиТатарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-7 карары (алга таба- карар) белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнешавыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгәтүбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 25.7 пункттаберенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Максатчан уку турында шартнамә төзү конкурсында Россия Федерациясенең дәүләт телен белүче, тиешле дәрәҗәдә беренче тапкыр һөнәри белем алучы һәм укуны тәмамлаганнан соң хезмәт мөнәсәбәтләре барлыкка килүгә китерә торган укучылар яисә башка шартнамә буенча йөкләмәләре булмаган гражданнар катнашырга хокуклы.".

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион

челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районының Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге башлыгы Р.Җ.Хәмизуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Түбән Тәкәнеш
авыл җирлеге башлыгы,
авыл җирлеге Советы рәисе /Р.Җ.Хәмизуллин/